**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 ноябрь, 2023 ел** **№ 342**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Красносельский авыл җирлеге» муниипаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2023 елның 14 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, 14.09. – 10.10.2023 гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керә торган Березовка п. Генераль планын раслау турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 221 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Генераль планына материаллар белән территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) УИН 9262244002020304202307111 буенча танышырга мөмкин.